Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул.Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы, Камай
авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

21 февраль 2025 ел № 1

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРДЫ :

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә::

1.1. файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. халык күплэп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар, борындыкларда һәм муенчакларда хуҗалары күзәтүе астында:

- Камай авылы Төньяк урамыннан 250 метр ераклыкта (чокыр буйлап);
- Камай авылының төньяк өлешендә, Тынычлык урамыннан 200 метр ераклыкта (чокыр буйлап);

Бу территорияләрдә «Этләрне йөртү» дигән язулы такталар урнаштырырга.

2.Балалар һәм спорт мәйданчыкларында, массакүләм ял итү урыннарында,балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектлары һәм кибетләр янындагы территорияләрдә йорт хайваннарын ирекле йөртүне тыярга.

Әлеге пунктның тәэсире озатып йөрүче этләргә кагылмый.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны җәмәгать урыннарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерегә, һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.М. Ахунҗанов